**Фәрваз МИҢНУЛЛИН,**
*әдәбият тәнкыйтьчесе, язучы-тәрҗемәче,1977-1984 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре, Чаллы төбәгендә яшәп иҗат итүче яшьләр белән иҗади элемтәдә тора.*

# АК КАЛА ЯШЬЛӘРЕ ИҖАТЫ ТУРЫНДА

Чаллыда «Ләйсән» исемле әдәби берләшмә булуын, ул берләшмә тирәсенә сәләтле яшь авторларның зур гына отряды тупланып килүен, билгеле, без һәммәбез дә белә идек. Шул яшьләрнең бер җыентыгын чыгарырга кирәк, дигән фикер дә күптән йөри иде. Ләкин гомерләр уза торды. КАМАЗның беренче чираты төзелеп бетеп, файдалануга тапшырылды. Чаллыдагы «Орфей» әдәби берләшмәсе членнарының «Город моей мечты» исемле җыентыгы басылып чыкты, ә «Ләйсән» яшьләренең күмәк җыентыгы һаман күренмәде.

Ниһаять, Чаллы төбәгендә яшәүче яшьләрнең беренче зона конференциясен уздырырга әзерләнеп йөргән көннәрдә, Равил Лотфуллин «Яшьлегем Чаллы» исемле җыентыкны Татарстан Язучылар союзына китереп тапшырды. Беренче кат танышканда ук кулъязмадагы әсәрләрнең күп өлеше әйбәт тәэсир калдырган иде. Чаллыга конференция уздырырга баргач, ул тәэсир тагын да көчәя һәм ныгый төште. Андагы яшьләр без уйлаганнан да көчлерәк, кызыклырак булып чыктылар...

...Кулъязманың поэзия өлеше шушы хәлендә үк бик әйбәт һәм матур тәэсир калдыра. Тагын шул ачык булып күзгә ташланып тора: Чаллыда шагыйрьләргә караганда шагыйрәләр күбрәк тә, көчлерәк тә икән. Аларның һәммәсе турында да сөйләп булмас, минем бары өч кыз турында гына берничә сүз әйтеп узасым килә. Алар – Рәйсә Фәхразиева, Тәнзилә Сәгыйтова һәм Сәлимә Шәрипова. Өчесе дә сәләтле, ләкин һәркайсы үзенчә сәләтле, бер-берләрен кабатламыйлар, бер-берләренә охшамаганнар.

Арада иң яше – Рәйсә Фәхразиева. Яшьлеге шигырьләреннән үк сизелеп тора. Барлык шигырьләре диярлек мәхәббәт турында. Яшь кызның беренче мәхәббәте кебек, шигырьләре бик сафлар һәм пакьләр, өрфиядәй җиңелләр, акварель буяуларыдай үтә күренмәлеләр. Аның шигырьләренә зәңгәр күкләр төсе, кыр казлары моңы сеңгән. Шигырьләрнең берсе икенчесенә кушылып килә, берсе икенчесенең дәвамы кебегрәк яңгырый. Шулай тау елгасыдай шаулап ага торган тоташ бер стихия, көчле бер ташкын хасил була.

Рәйсә Фәхразиеваның күп кенә шигырьләре көйгә салуны сорый, көй кебек агылып, җырлап тора һәм аның иҗаты үзе дә халык авыз иҗатыннан, халыкның мәхәббәт җырларыннан үсеп чыккандыр төсле. Шигырьләренең яңгырашы, образлары һәм чагыштырулары халык җырларына тартым.

Өлкән шагыйребез Хәсән Туфан: кешенең шагыйрьлеген бер уңышлы юлдан белеп була, – дигән иде. Андый юлларны Рәйсәнең һәр шигыреннән диярлек табарга була:

Туган ягым – каенлы як...
Тәүге җырларым аңа.
Чишмәсеннән гади түгел
Каен сулары ага.

*(«Туган җирем – каенлы як»)*

Язылачак җырларыма
Кыр казлары моңы күчкән.

*(«Кыр казлары»)*

Күз яшьләре булып чык җемелди –
Үткән җәйләремнән хатирә.

*(«Сандугачлар саубуллашты»)*

Кыңгыраулар – минем туган якта
Торып калган күңел күзләрем.

*(«Кыңгыраулар көен тыңладым»)*

Мондый юлларны күп китерергә булыр иде. Алар безнең поэзиягә кызыклы һәм сәләтле яңа бер шагыйрә килүе хакында сөйлиләр.

Әгәр Рәйсә әдәбиятка халык авыз иҗатыннан, халыкның мәхәббәт җырларыннан килсә, Тәнзилә Сәгыйтова шигырьләрендә язма әдәбиятка, Г. Тукай, М. Җәлил, Ф. Кәримнәргә якынлык сизелә. Ул табигать күренешләренә символик мәгънә салырга, аларны кеше хисләрен ачканда файдаланырга ярата. Тәнзиләнең күп кенә шигырьләре балладага тартым. Тормышны драматик каршылыклары белән күрә һәм күрсәтә белә. Шигырьләре буенча ул тормышның ачысын-төчесен, шатлыгын-кайгысын күп күргән тәҗрибәле кеше булып күз алдына килә. Шигырьләреннән фәлсәфи тирәнлек, драматизм сизелеп тора. Тәнзилә дә мәхәббәт турында күп яза. Әмма, башкалардан аермалы буларак, олы мәгънәдәге, тормышның, яшәешнең асылын тәшкил иткән мәхәббәт турында яза.

Сәлимә Шәрипова Рәйсәгә дә, Тәнзиләгә дә ошамаган, аларның һәр икесеннән дә аерылып тора. Шигырьләре ирләрчә нык кул белән язылган, өлгергән фикерле, кырыс хисле. Сәлимә үзен дөньяның, тормышның хуҗасы итеп сизә. Аның тормыш күренешләренә якын килүе дә үзенчә. Тормыш күренешләрен ул без уйламаган, көтмәгән яктан ача белә. Бу – оригиналь талант билгеле.

Әгәр шушы өч кеше булмаса, мин Фирая Хәлиуллина, Венера Хәбибрахманова шигырьләре хакында да җылы сүзләр әйтә алган булыр идем. Икесе дә күптән язып киләләр, икесенең дә әйбәт шигырьләре бар. Ләкин шактый традицион итеп язалар, үз йөзләрен, үз төсләрен чамалавы кыенрак.

Инде шагыйрьләргә килгәндә, иң элек, М. Газизов белән Х. Хөснуллинны аерым күрсәтергә кирәк. Аларның һәр икесе – шигырь сөючеләргә яхшы таныш. М. Газизов – берничә китап чыгарган кеше. Китаплары матбугатта әйбәт бәя алды. Чаллыдагы конференция вакытында ул СССР Язучылар союзына тәкъдим ителергә лаек табылды. Берәр елдан нәшриятта Х. Хөснуллинның аерым җыентыгы чыгар төсле. Алар бу җыентыкта да иң әйбәт шигырьләре белән катнашалар.

Шагыйрьләрдән тагын ике кешене билгеләп үтәсе килә. Аларның берсе – Рәсим Абдуллин «Чаян» журналында күп кенә шигырьләр, мәсәлләр бастырган кеше. Сатирик һәм юмористик әсәрләр язарга кулы ятып торган егет. Икенчесе – Миркадәм Матшин, бөтенләй яңа исем. Балалар психологиясен яхшы белә, балаларча итеп яза белә.

Гомумән, «Яшьлегем Чаллы» җыентыгы тупланган поэзия әсәрләре җылы тәэсир калдыра...

*// Якты юл. – 1978. – 18 февр.*